**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** 31.08.2018

Казан шәһәре

**БОЕРЫК** 870-п

**Чаллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасын оештыру проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга 2018 елның 15 августындагы ТАТ НЧН 01969 ВЭ лицензияне, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2017 елның 8 декабрендәге дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында №16.11.11.000.Т.003231.12.17 санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Чаллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ тарафыннан тәкъдим ителгән аллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасын оештыру проекты нигезендә **боерык бирәм:**

1. Чаллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасын оештыру проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә Чаллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ җир астыннан су алу корылмасында санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә «Чаллы «индустриаль паркы» ҖЧҖ хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итүнең җир астыннан су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Чаллы шәһәре Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Чаллы шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәге чараларны үткәрү турында тәкъдим итәргә:

Чаллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зоналарының чикләре, су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалыкта файдалану кагыйдәләре һәм режимнары турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
31.08.2018 № 870-п
боерыгына 1 нче кушымта

**Чаллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре**

Су алу җайланмасы Минзәлә тракты, 96 адресы буенча урнашкан №1 скважинадан тора.

Җир асты байлыклары кишәрлеге Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгыш өлешендә, Кама елгасының сул як ярында (Түбән Кама сусаклагычы) урнашкан.

№1 су алу скважинасының географик координатлары: төньяк киңлектәге $55^{0}41'32,54''$, көнчыгыш озынлыктагы $52^{0}25'18,47''$.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык суүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы

«Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ су алу корылмасының беренче поясы чиге скважина авызыннан 30 метрлы радиус белән билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы

«Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ җир астыннан су алу корылмасының икенче поясы санитар саклык зонасының беренче поясы дәрәҗәсендә билгеләнә: 30 м.

Санитар саклык зонасының III поясы

«Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ №1 су алу скважинасының санитар саклык зонасының өченче поясы 150 метрлы радиус белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
31.08.2018 № 870-п
боерыгына 2 нче кушымта

**Чаллы шәһәрендә «Чаллы» индустриаль паркы» ҖЧҖ хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.